КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 июль г.Казань № 663

Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү» 2022 елның 23 июнендәге УП-438 номерлы Указын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы тора дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына Тәртипкә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 11 июль, 663 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында төзелгән
«Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга
бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Бу Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операция чорында Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне (алга таба – шул ук эзлеклелектә гариза бирүче, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирү механизмын билгели.

2. Бер тапкыр бирелә торган түләү 260,0 мең сум күләмендә бирелә.

3. Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен гариза бирүче Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына түбәндәгеләрне тапшыра:

бу Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча бер тапкыр бирелә торган түләүгә гариза;

хәрби хезмәт итүгә хәрби часть исемлекләренә гариза бирүчене кертү турындагы боерыктан өземтә күчермәсен;

кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитлары бирелгән документ күчермәсен;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан билгеләнгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче шәхесен таныклый торган документын күрсәтә.

4. Бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, контракт буенча хәрби хезмәт итүгә сайлап алу пункты (1 разрядлы, Казан шәһәре) белән берлектә, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу өчен Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннары Россия Федерациясенең дәүләт чиген чыкканнан соң, бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча шәхси счетларга акча күчерү өчен Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затлар исемлеген Министрлыкка кертә.

5. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, контракт буенча хәрби хезмәт итүгә сайлап алу пункты (1 разрядлы, Казан шәһәре) белән берлектә, бу Тәртипнең 4 пункты нигезендә Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге

өчен җавап бирә.

6. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, контракт буенча хәрби хезмәт итүгә сайлап алу пункты (1 разрядлы, Казан шәһәре) белән берлектә, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 9 статьясы нигезендә гариза бирүчеләрнең Министрлык тарафыннан шәхси мәгълүматлары эшкәртелүгә ризалыгын алуны тәэмин итә.

7. Министрлык, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, контракт буенча хәрби хезмәт итүгә сайлап алу пункты (1 разрядлы, Казан шәһәре) белән берлектә, гариза бирүчеләрнең алынган шәхси мәгълүматларының конфиденциальлеген һәм сакланышын тәэмин итә, аларны хокуксыз файдаланган өчен Федераль закон нигезендә җавап бирә.

8. Гариза бирүчеләрнең кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган түләү суммасын күчерү Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты тарафыннан Министрлыкка Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затлар исемлеге тапшырылган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә башкарыла.

9. Министрлык ел саен, бер тапкыр бирелә торган түләү гамәлгә ашырылган елдан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап тапшыра.

Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы хәрби комиссары
______________________________ ка (кә)
(фамилиясе, инициаллары)
____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
_________________________ дан/тан/нан,
теркәлү адресы: _______________________
_____________________________________
(гариза бирүченең почта индексы, яшәү урыны адресы
_____________________________________
(булу урыны))
_____________________________________,
гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документ: ____________________________
(сериясе, номеры)
_____________________________________,
(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
СНИЛС ______________________________,
элемтәгә керү телефоны ________________

## Гариза

______________________________да хәрби хезмәт узуга бәйле рәвештә, миңа 260,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләвегезне үтенәм.

Билгеләнгән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне ___________________
(кредит оешмасы исеме)
______________________________________________________________________ ачылган ________________________________ номерлы счетка күчерүегезне үтенәм.

Дата____________

____________________
(гариза бирүченең имзасы)

Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы хәрби комиссары __________ /________________/
(имзасы) (фамилиясе, инициаллары)
раслыйм

20____ ел, «_____»________

20___ елның ________________ дагы (ындагы)
шәхси счетларга акча күчерү өчен Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затлар исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Кредит оешмасының исеме | Кредит оешмасының ИНН/КППы | Кредит оешмасының БИКы | Кредит оешмасында шәхси счет номеры | Суммасы, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | Барлыгы | |

Башкаручы ________________/________________/
(имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

________________________________________